**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет Балтачевского сельского поселения Азнакаевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы Балтач авыл җирлеге башкарма комитеты**

ул. Молодежная д.1А, село Балтачево,
Азнакаевского муниципального района
РТ, 4233302
Тел. (8-885592) 44723

Яшьлэр урамы ,1А, Балтач авылы
Азнакай муниципаль районы ТР,
423302
Тел. (8-885592) 44723

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«01» сентября 2016 ел № 15

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Балтач авыл җирлеге башкарма комитеты муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксыну барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибе турында

«Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәм «Россия Федерациясенең аерым дәүләт вазыйфаларын, федераль дәүләт хезмәте Вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынуы барлыкка килү турында Россия Федерациясе Президентының 2015 елның 22 декабрендәге 650 номерлы Указы нигезендә һәм Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» карары нигезендә, карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Балтач авыл җирлеге башкарма комитеты муниципаль хезмәткәрләре вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксыну барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибе хакында кушымтада бирелә торган нигезләмәне расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башлык Л.Л. Хәбипов

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Балтач авыл җирлеге Башкарма комитетының 2016 елның 01 сентябрендәге 15 номерлы карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Балтач авыл җирлеге Башкарма комитетының муниципаль хезмәткәрләре вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксыну барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибе турында Нигезләмә**

1. Әлеге Нигезләмәдә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Балтач авыл җирлеге Башкарма комитетының муниципаль хезмәткәрләре вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксыну барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибе билгеләнә.

2. Муниципаль хезмәткәрләр Россия Федерациясенең коррупциягә каршы көрәш турындагы законнары нигезендә вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксыну барлыкка килү турында хәбәр итәргә, шулай ук мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яисә җайга салу буенча чаралар күрергә тиеш.

Хәбәр вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксыну барлыкка килү турында язма рәвештә рәсмиләштерелә (алга таба-хәбәрнамә).

3. Муниципаль хезмәткәрләр яллаучы вәкиленә әлеге Нигезләмәгә кушымтада каралган форма буенча төзелгән хәбәрнамә җибәрәләр.

4. Азнакай муниципаль районының Балтач авыл җирлеге башлыгы адресына килгән хәбәрнамәләр карау өчен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә, муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның вазыйфаи тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясенә (алга таба – Комиссия) тапшырыла.

Хәбәрнамәләрне алдан карау барышында Комиссия хәбәрнамәләр, аларда бәян ителгән хәлләр буенча аңлатмалар җибәргән затлардан билгеләнгән тәртиптә алырга һәм федераль дәүләт хакимияте органнарына, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм кызыксынган оешмаларга билгеләнгән тәртиптә запрослар җибәрергә хокуклы.

5. Мөрәҗәгатьләрне алдан карау нәтиҗәләре буенча аларның һәркайсына дәлилләнгән бәяләмә әзерләнә.

Хәбәрнамәләрне алдан карау барышында алынган хәбәрнамәләр, бәяләмәләр һәм башка материаллар комиссия утырышына тапшырыла, ул комиссиягә хәбәрнамәләр кергән көннән алып җиде эш көне эчендә үткәрелә.

Әлеге Нигезләмәнең 4 пунктының икенче абзацында күрсәтелгән гарызнамәләр җибәрелгән очракта, Азнакай муниципаль районының Балтач авыл җирлеге башлыгына хәбәрнамәләр кергән көннән алып 45 көн эчендә комиссиягә хәбәрнамәләр, бәяләмәләр һәм башка материаллар тапшырыла. Күрсәтелгән срок озайтылырга мөмкин, ләкин ул 30 көннән дә артмаска тиеш.

6. Комиссия белдерүләрне карый һәм алар буенча карарларны «муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә, муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның вазыйфаи тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе турында Нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Азнакай район Советының 2016 елның «18» августындагы 64-9 номерлы карары белән расланган Комиссия хакындагы нигезләмәдә билгеләнгән тәртиптә кабул итә һәм кабул ителгән карарны Азнакай муниципаль районының Балтач авыл җирлеге.

7. Азнакай муниципаль районының Балтач авыл җирлеге башлыгы белдерүләрне карау нәтиҗәләре буенча комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә::

а) хәбәрнамә җибәргән зат вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликты булмавын танырга;

б) хәбәрнамә юллаган затның вазыйфаи бурычларын үтәгәндә шәхси кызыксынуы мәнфәгатьләр конфликтына китерә яисә китерергә мөмкин дип танырга;

в) хәбәрнамә юллаган зат тарафыннан мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау һәм (яисә) җайга салу чаралары үтәлмәгәнлеген танырга.

8. Әлеге Нигезләмәнең 7 пунктындагы «б» пунктчасында каралган карар кабул ителгән очракта, Азнакай муниципаль районының Балтач авыл җирлеге башлыгы Россия Федерациясе законнары нигезендә мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу буенча чаралар күрә яисә чаралар күрүне тәэмин итә йә хәбәрнамә җибәргән Затка мондый чаралар күрергә тәкъдим итә.

10. Әлеге Нигезләмәнең 7 пунктындагы «в» пунктчасында каралган карар кабул ителгән очракта, Азнакай муниципаль районының Балтач авыл җирлеге башлыгы Россия Федерациясе законнарында каралган юридик җаваплылык чараларын куллана.

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Балтач авыл җирлеге Башкарма комитетының муниципаль хезмәткәрләре вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксыну барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибе турында Нигезләмәгә кушымта

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Балтач авыл җирлеге Башлыгына

______________________________________

( Ф.И.А.и, вазифа)

Вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган
яисә китерергә мөмкин шәхси кызыксыну барлыкка килү турында хәбәрнамә

Вазыйфаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынуым тууы турында хәбәр итәм (кирәклесен ассызыкларга).
Шәхси кызыксыну барлыкка килүгә нигез булып торган хәлләр: _______________________________________________________

__________________________________________________________________________

Үтәлешенә шәхси кызыксыну йогынты ясый торган яисә йогынты ясарга мөмкин булган вазыйфаи бурычлар: ______________________________________

__________________________________________________________________________

Мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яисә җайга салу буенча тәкъдим ителә торган чаралар: ______________________________________________________

__________________________________________________________________________

Муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә, муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның вазыйфаи тәртибенә таләпләрне үтәү һәм әлеге белдерүне карагандa мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе утырышында шәхсән катнашырга ниятлим (ниятләмим).

«___»________________20__ел. _________________________ ____________________

*(хәбәрнамә җибәрүче затның имзасы)* *(имзаның расшифровкасы )*

Башлык Хәбипов Л.Л.